**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Борискинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**

**Борис авыл Жирлеге**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422883, РТ, с. Борискино, ул. Дружбы, 8
тел: : 8 (84346) 76-239

Адресы: 422883, РТ, Борис авылы, Дуслык ур., 8
факс: 8 (84346) 76-239

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Борис авылы **КАРАР**

2024 елның 29 июле 85№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 статьясы нигезендә Борис авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 10 октябрендәге 101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә 1нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Борис авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы, Әлки районы, Борис авылы, Дуслык ур., 8 йорт (җирле үзидарә бинасы), Борис авылы, Дуслык ур., 8 йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча махсус җиһазландырылган стендларда урнаштырырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru. сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Борис авыл җирлеге башлыгы,
Советы Рәисе Г.В Самарина

Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советының 29.07.2024 ел, 85 номерлы карарына1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**5 статьяда (җирлекнең жирле әһәмияттәге мәсьәләләре):**

5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"30) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

**16.1 статьяда («авыл торак пункты старостасы»):**

16.1 статьяның 5 пунктындагы 2 абзацында "1-7 пунктларында" сүзләрен "1-7 һәм 9.2 пунктларында"сүзләренә алмаштырырга.;

**38 статьяда ("җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату"»:**

38 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасы өстәргә:

9.1) аның чит ил агенты статусын алуы;

**47 статьяда (җирлек башкарма комитеты вәкаләтләре):**

1 пунктның 6 пунктчасындагы 8 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр

сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

**69 статьяда ("муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе"):**

69 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"69 маддә. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы җирлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып алар:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru ЭЛ № ФС77-60244 массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән 17.12.2013 Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор);

2) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Борис авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру (www.alkeevskiy.tatarstan.ru.);

3) түбәндәге мәгълүмат стендларында урнаштыру: РТ, Әлки районы, Борис авылы, , Дуслык ур., 8

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен китапханә системасы учреждениеләрендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: РТ, Әлки районы, Борис авылы, , Дуслык ур., 8

4. Җирлек норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 7 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудаң тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге хокукый Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге башлыгы актын».